**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы № 132 «05» сентябрь 2015 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегенең 2012 елның 18 апрелендәге 35 номерлы карары (2015 елның 16 февралендәге 114 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 29 июнендәге 187-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 3 пункты нигезендә

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк Советының 2012 елның 18 апрелендәге 35 номерлы (2015 елның 16 февралендәге 114 номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә, җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән йә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу өчен таләп ителгән очраклардан тыш, үзгәреш кертергә; “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш;” сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2015 елның 30 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.Җ.Абдулвәлиева